ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.09.2025 ел Баулы шәһәре №115

2025/2026 уку елында Баулы муниципаль районында «Өченче буын университеты» проектын гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2025 - 2030 елларга «Актив озак яшәү» республика программасын (комплексны планны) раслау турында» 2024 елның 26 декабрендәге 1213 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль районында «Гаилә» милли проектының «Өлкән буын» федераль проектын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2025/2026 уку елында Баулы муниципаль районы учреждениеләре базасында «Өченче буын университеты» проектын гамәлгә ашыру кысаларында пенсия яшендәге һәм пенсия алды яшендәге кешеләрне заманча белемнәр нигезләренә өйрәтүне оештырырга.

2. Татарстан Республикасы буенча Россия социаль фонды бүлегенең Баулы районындагы Клиент хезмәте (бүлек хокукларында) җитәкчесенә (алга таба - Социаль фондның клиентлар хезмәте) «Өченче буын университеты» проектын гамәлгә ашыру кысаларында заманча белем нигезләренә өйрәнергә теләүче пенсионерлардан гаризалар кабул итүне оештырырга тәкъдим итәргә.

3. Пенсия яшенә җиткән һәм пенсия алды яшенә җиткән гражданнарны укыту дәресләрен һәм урыннарын билгеләргә:

- Гарәп теле - Социаль фондның Клиент хезмәте (Баулы шәһәре, Һади Такташ ур., 21 йорт, 10 нчы кабинет);

- Мәдәният һәм мәгариф - Социаль фондның Клиент хезмәте (Баулы шәһәре, Һади Такташ урамы, 21 йорт, 10 нчы кабинет);

- ЗОЖ нигезләре - Баулы муниципаль районының «Нефтьче» спорт комлексы (Баулы шәһәре, Октябрь мәйданы, 17 йорт), Баулы муниципаль районының «Исергәп урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ (Баулы районы, Исергәп авылы, 80 йорт), Уба авыл клубы -

Баулы муниципаль районының «Үзәк клуб системасы - Район мәдәният йорты» МБУ 12 нче филиалы (Баулы районы, Уба авылы, Центральная урамы, 25а йорты);

- Сәламәт яшәү рәвеше нигезләре - бию терапиясе - Муса Җәлил исемендәге мәдәният йорты (Баулы шәһәре, Ленин ур., 13);

- Компьютер белеме нигезләре - Социаль фондның Клиент хезмәте (Баулы шәһәре, Һади Такташ урамы, 21 йорт, 10 нчы кабинет);

- Компьютер белеме нигезләре - смартфоннар - социаль фондның Клиент хезмәте (Баулы шәһәре, Һади Такташ урамы, 21 йорт, 10 нчы кабинет).

4. Әлеге карарның 3 нче пунктында күрсәтелгән учреждениеләр җитәкчеләренә «Өченче буын университеты» проектын гамәлгә ашыру кысаларында заманча белем нигезләре буенча дәресләр үткәрү өчен шартлар һәм мөмкинлекләр тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров